**Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Микулино авылы №72 "22"12. 2022 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 гыйнварендәге 91 номерлы авыл җирлеге Советының карары белән расланган, Азнакай муниципаль районы « Микулино авыл җирлеге» җирдән файдалану һәм муниципаль берәмлек төзелеше кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында (19.11.2016 №44, 03.07.2017 №56, 04.09.2017 №63, от 25.12.2017 №83, 03.03.2018 №101, 23.09.2019 №130, 02.03.2020 №160, 16.08.2021 №28/1, 24.06.2022 №59, 05.12.2022 №67 карарлар редакциясендә)

Муниципаль норматив хокукый актларны Россия Федерациясенең гамәлдәге шәһәр төзелеше кодексына туры китерү һәм 2022 елның 14 июлендәге 350-ФЗ номерлы «Россия Федерациясенең шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында " Федераль законны үтәү максатыннан

Микулино авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 гыйнварендәге 91номерлы авыл җирлеге Советының карары белән расланган, Азнакай муниципаль районы «Микулино авыл җирлеге» җирдән файдалану һәм муниципаль берәмлек төзелеше кагыйдәләренә (19.11.2016 №44, 03.07.2017 №56, 04.09.2017 №63, от 25.12.2017 №83, 03.03.2018 №101, 23.09.2019 №130, 02.03.2020 №160, 16.08.2021 №28/1, 24.06.2022 №59, 05.12.2022 №67 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 25 статьяның 2 өлешендәге 4 пунктын «, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган критерийлар» сүзләре белән тулыландырырга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://aznakayevo.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл жирлеге Советының торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис И.А.Такиулин